| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

28.12.2023 г. Зеленодольск № 354

Зеленодольск муниципаль районы Советының «Муниципаль контроль төрләре исемлеген, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль контроль төрләре һәм аны гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органнары исемлеген алып бару тәртибен раслау турында» 2020 елның 20 маендагы 490 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

2008 елның 26 декабрендәге «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» 294-ФЗ номерлы Федераль закон, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Советының «Муниципаль контроль төрләре исемлеген, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль контроль төрләре һәм аны гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органнары исемлеген алып бару тәртибен раслау турында» 2020 елның 20 маендагы 490 номерлы карарына (алга таба - Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль контроль төрләре исемлеген алып бару тәртибенең II бүлегенең 2.1 пунктындагы 3 пунктчасын төшереп калдырырга;

1.2. Карарның 2 нче кушымтасын, әлеге карарга 1 нче кушымтада каралганча, яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

**Зеленодольск муниципаль районы**
**Башлыгы, Советы Рәисе** **М.П. Афанасьев**

Зеленодольск муниципаль районы Советының
2023 елның 28 декабрендәге
354 номерлы карарына
1 нче кушымта

«Зеленодольск муниципаль районы Советының
2020 елның 20 маендагы
490 номерлы карарына
2 нче кушымта

## Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль контроль төрләре һәм аны гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органнары исемлеге

| № т/б | Муниципаль контроль төренең атамасы | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органы исеме (урнашкан урыны, телефоны) |
|---|---|---|
| 1 | Муниципаль җир контроле (Зеленодольск шәһәре һәм ЗМР авыл җирлекләре чикләрендә) | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты (Зеленодольск шәһәре, Ленин ур., 41а тел. 8 (84371) 5-78-27 |
| 2 | Муниципаль торак контроле (Зеленодольск шәһәре һәм ЗМР авыл җирлекләре чикләрендә) | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты (Зеленодольск шәһәре, Ленин ур., 41а тел. 8(84371) 4-97-47 |
| 3 | Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль (Зеленодольск шәһәре һәм ЗМР авыл җирлекләре чикләрендә) | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты (Зеленодольск шәһәре, Ленин ур., 41а тел. +7 (84371) 5-77-74 |
| 4 | Бердәм җылылык белән тәэмин итә торган оешманың җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү буенча йөкләмәләрен үтәлешенә муниципаль контроль (Зеленодольск шәһәре һәм ЗМР авыл | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты (Зеленодольск шәһәре, Ленин ур., 41а тел. 8(84371) 4-97-47 |

| | | |
|---|---|---|
| | җирлекләре чикләрендә) | |
| 5 | Автомобиль транспортында, шәһәр, җир өсте, электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль(Зеленодольск шәһәре һәм ЗМР авыл җирлекләре чикләрендә) | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты (Зеленодольск шәһәре, Ленин ур., 41а тел. 8(84371) 5-97-02 |